**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 2 апрелендәге 962 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 2 июнендәге 1540 номерлы**
**«“2021-2025 елларда Казан шәһәре территориясендә**
**тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү”**
**муниципаль программасын раслау турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«2021-2025 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү» муниципаль программасының финанс күрсәткечләрен 2025 елга бюджет гаризасына туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 2 июнендәге 1540 номерлы «“2021-2025 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү” муниципаль программасын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 12 апрелендәге 850 номерлы, 2022 елның 18 апрелендәге 1153 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 917 номерлы, 2023 елның 3 июлендәге 1857 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 1289 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. программа паспортында «Программаны елларга һәм чыганакларга бүлеп финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

<table>
<tr><td>«Программаны елларга һәм чыганакларга бүлеп финанслау күләме</td><td>Финанслауның гомуми күләме 97 221,2 мең сум тәшкил итә. Программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Ул, Казан шәһәре бюджеты проектын тиешле финанс елына һәм план чорына формалаштырганда, ел саен төгәлләштерелергә тиеш
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>барлыгы</th><th>Казан шәһәре муниципаль бюджеты</th><th>бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2021</td><td>17 353,7</td><td>17 353,7</td><td>-</td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2022 | 18 957,7 | 18 957,7 | - |
| | 2023 | 22 053,0 | 22 053,0 | - |
| | 2024 | 22 004,1 | 22 004,1 | - |
| | 2025 | 16 852,7 | 16 852,7 | - |
| | **БАРЛЫГЫ** | **97 221,2** | **97 221,2** | -» |

1.2. III «Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» бүлегендә таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Мең сум

| Чаралар | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 нче төп чара. Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенең тышкы реклама өлкәсендәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү (аппаратны агымдагы карап тоту) | 17 046,7 | 18 650,7 | 21 591,0 | 21 542,1 | 16 390,7 |
| 2 нче төп чара. Законсыз урнаштырыла торган реклама корылмаларын оператив рәвештә мәҗбүри сүтүне тәэмин итү | 307,0 | 307,0 | 462,0 | 462,0 | 462,0 |
| **БАРЛЫГЫ** | **17 353,7** | **18 957,7** | **22 053,0** | **22 004,1** | **16 852,7»** |

1.3. муниципаль программаның 1 номерлы кушымтасын әлеге карар кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 2 апрелендәге
962 номерлы карарына
кушымта

**Муниципаль программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм «2021-2025 елларга Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү» муниципаль программасы чаралары буенча финанслау**

| Төп чаралар исеме | Башка ручы лар | Төп чаралар ны үтәү вакыт лары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлек ләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | База елы | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Максат: Казан шәһәрендә тышкы реклама базарының инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| **1 бурыч. Шәһәр инфраструктурасының социаль әһәмияткә ия объектларында реклама чыганаклары санын арттыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Шәһәр инфраструктурасының социаль әһәмияткә ия объектларында реклама корылмаларын урнаштыруга рөхсәтләр бирү | | | Шәһәр инфраструк турасының социаль әһәмияткә ия объектларында реклама корылмала рын урнаштыру га рөхсәтләр бирү | 118 | 182 | 244 | 306 | 348 | 390 | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2 бурыч. Казан шәһәрендә тышкы реклама өлкәсен үстерү өчен шартлар тудыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Тышкы реклама һәм мәгьлүмат идарәсенең тышкы реклама өлкәсендәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү (аппаратны агымдагы карап тоту) | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе | 2021-2025 еллар | Казан шәһәре Башкарма комитеты Тышкы реклама һәм мәгьлүмат идарәсенең тышкы реклама өлкәсендәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне башкару буенча эшчәнлеген гамәлгә ашыру хисабына Казан шәһәре бюджетына керем, мең сум | 232975 | 3350 39 | 322949 | 39300 0 | 308000 | 308000 | 17046,7 | 18650,7 | 21591,0 | 21542,1 | 16390,7 |
| 2.2. Ачык сатулар уздыруны тәэмин итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм | 2021-2025 еллар | Гомуми файдаланудагы сату мәйданчык ларында электрон рәвештә үткәрелә торган сатулар | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәгълүмат идарәсе | | өлеше, сатуларның гомуми санынннан процентлар да | | | | | | | | | | | |
| 2.3. Законсыз урнаштырылаторган реклама корылмаларны оператив рәвештә мәҗбүри сүтүне тәэмин итү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе | 2021-2025 еллар | Казан шәһәре территориясендә законсыз урнаштыры латорган реклама корылмаларының уртача еллык өлеше, реклама корылмаларының гомуми санынннан процентлар да | 0,26 | <0,23 | <0,20 | <0,18 | <0,16 | <0,14 | 307,0 | 307,0 | 462,0 | 462,0 | 462,0 |
| **Программа буенча БАРЛЫГЫ: 97 221,2 мең сум** | | | | | | | | | | 17354,7 | 18957,7 | 22053,0 | 22004,1 | 16852,7 |